РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 07 » 10 2025 ел № 996

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 29.07.2025 № 763 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны 2025-2026 елларда тукландыруны оештыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 № 273-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны кайнар туклануның уртача бәясен раслау турында» 2024 елның 12 сентябрендәге 777 санлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 16 сентябрендәге 789 санлы карары белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативына үзгәреш кертү турында»гы 2025 елның 27 маендагы 362 санлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына акчалата түләүләр турында»гы 2024 елның 10 сентябрендәге 755 санлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында»гы 20.10.2022 № 1122 карары, РФ Баш дәүләт санитария табибының «2.4.3648-20 СП санитария кагыйдәләрен раслау турында»гы 28.09.2020 № 28 карары нигезендә,

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Башкарма комитеты к а р а р  б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 29.07.2025 №763 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны 2025-2026 елларда тукландыруны оештыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктындагы алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Комиссия үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы:".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.М Якупов
тел. 2-42-05